ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

01.06.2023 Казан ш. № 55

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2021 елның 15 мартындагы 18 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актын федераль законнарга яраштыру максатларында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында» 2021 елның 15 мартындагы 18 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2023 елның 22 февралендәге 12 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфасын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен билгеләнгән башка квалификация таләпләренә туры

килүен тикшерүдән һәм шундый бәяләү һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп кую өчен дәгъва итүчеләр арасыннан гражданинны яки граждан хезмәткәрен билгеләүдән гыйбарәт.»;

1.7 пунктта:

өченче абзацта «кече вазыйфалар төркеменә» сүзләрен сүзләрне «кече вазыйфалар төркеменә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«федераль законнарда каралган башка очракларда.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Гражданин (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми:

а) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата, граждан хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле;

б) белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлек һәм әзерлек юнәлешләренең зурайтылган төркемнәренә), һөнәри яңадан әзерлекнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата квалификация таләпләренә (граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасын) биләү өчен квалификация таләпләрендә шундый таләпләр каралган очракта) туры килмәве сәбәпле;

в) граждан хезмәтенә керү һәм аны узуга бәйле чикләүләргә һәм Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында законнарына бәйле рәвештә.»;

3.4 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белем һәм (яки) квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданинның теләге буенча хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турындагы документлар күчермәләре;»;

4.1 пунктта «бәяләү методларын сайлау» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗәдәге,» сүзләрен өстәргә;

4.5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданинның (граждан хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте стажына яисә белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә, һөнәри дәрәҗәгә квалификация таләпләренә, шулай ук, Инспекция җитәкчесенең тиешле карары булганда – өстәмә яңадан һөнәри әзерлек үзләштерү нәтиҗәләре буенча белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (эреләндерелгән белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре төркемнәренә карата), квалификациягә карата таләпләргә туры килүен тикшерү.»;

4.11 пунктның өченче абзацында «комиссия тарафыннан» сүзеннән соң «профессиональ дәрәҗәдәге» сүзләре белән тулыландырырга;

4.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны белеме һәм (яки) квалификация турында, граждан яки башка дәүләт граждан хезмәтен үтү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында алар тарафыннан

тапшырылган документларга нигезләнеп, шулай ук федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган конкурс процедуралары нигезендә бәялиләр, аларга тест уздыру, анкета, шәхси әңгәмә, реферат язу һәм башка язма эшләр кертелергә мөмкин. Бәйге үткәрелә торган төркем һәм вазыйфалар категориясенә карап, төрле бәяләү ысуллары кулланыла ала. Бу вакытта кандидат белән тест һәм шәхси әңгәмә уздыру барлык кандидатлар өчен дә мәҗбүри методлар булып тора.

Конкурс барышында кандидатларның һөнәри дәрәҗәләрен чагыштыру, аларның һөнәри белем дәрәҗәләрен, граждан хезмәте яки әзерлек юнәлеше буенча эш стажын, шулай ук аларның белгечлекләрен, әзерлек юнәлешләрен (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең зурайтылган төркемнәрен), һөнәри яңадан әзерлекнең өстәмә һөнәри программаларын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификацияләрне чагыштыру гамәлгә ашырыла (граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасын) биләү өчен квалификация таләпләрендә шундый таләпләр каралган очракта).

Инспекция тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.»;

4.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.15. Әгәр конкурс нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасын) биләү өчен кирәкле һөнәри дәрәҗәгә ия булган кандидатлар ачыкланмаса, яллаучы вәкиле кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итә ала.»;

4.16 пунктның беренче абзацында «граждан хезмәте, әмма» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗә,» сүзләрен өстәргә.

Җитәкче В.А. Кудряшов